КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2022 ел, 6 июнь г.Казань № 521

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Муниципаль берәмлекләрнең чыгым йөкләмәләре үтәлешен финанслар белән тәэмин итү өчен Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре бюджетларына Татарстан Республикасы бюджетыннан башка бюджетара трансфертлар бирү тәртибен раслау турында» 2019 ел, 28 март, 233 нче карары белән расланган Муниципаль берәмлекләрнең чыгым йөкләмәләре үтәлешен финанслар белән тәэмин итү өчен Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре бюджетларына Татарстан Республикасы бюджетыннан башка бюджетара трансфертлар бирү тәртибенә үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Муниципаль берәмлекләрнең чыгым йөкләмәләре үтәлешен финанслар белән тәэмин итү өчен Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре бюджетларына Татарстан Республикасы бюджетыннан башка бюджетара трансфертлар бирү тәртибен раслау турында» 2019 ел, 28 март, 233 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2019 ел, 5 август, 646 нчы карары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Муниципаль берәмлекләрнең чыгым йөкләмәләре үтәлешен финанслар белән тәэмин итү өчен Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре

бюджетларына Татарстан Республикасы бюджетыннан башка бюджетара трансфертлар бирү тәртибенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

2 пунктка түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«Башка бюджетара трансфертлар территорияләрендә хисап аеннан соң килүче айның 1 сенә һөнәри керемгә салым буенча Татарстан Республикасы бюджетына бурычы булган салым түләүчеләр булмаган муниципаль район составына керүче шәһәр округларының һәм җирлекләрнең чыгым йөкләмәләрен үтәүне финанс белән тәэмин итүгә бирелә.»;

6 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«6. Хисап аенда і-муниципаль берәмлек (МТі) өчен башка бюджетара трансфертлар күләме түбәндәгечә билгеләнә:

а) і-муниципаль район өчен түбәндәге формула буенча:

$$МТі=\sum_{j=1}^{n} НПДj\,,$$

монда:

n – әлеге Тәртипнең 2 пункты таләпләренә туры килә торган, хисап аена Татарстан Республикасы бюджетына үз территорияләрендә теркәлгән салым түләүчеләрдән һөнәри керемгә салым кергән территорияләрдән муниципаль район составына керүче авыл һәм шәһәр җирлекләре саны;

НПДj – j-шәһәр, авыл җирлеге территориясендә теркәлгән салым түләүчеләрдән хисап аенда Татарстан Республикасы бюджетына кергән һөнәри керемгә салым суммасы, сум;

б) і-шәһәр округы өчен түбәндәге формула буенча:

$$МТі = НПДі,$$

монда НПДі - әлеге Тәртипнең 2 пункты таләпләренә туры килә торган і-шәһәр округы территориясендә теркәлгән салым түләүчеләрдән хисап аенда Татарстан Республикасы бюджетына кергән һөнәри керемгә салым суммасы, сум.».

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин